СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-43 от «27» мая 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2025 елның 20 мартындагы 35-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2019 елның 31 октябрендәге 10-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12.1 пунктындагы “яисә башка федераль законнар, һәм гавами сервитут” сүзләрен “һәм (яисә) башка федераль законнар, һәм (яисә) гавами сервитут” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 6.7. пунктның 5 абзацын үз көчен югалтты дип танырга;

1.3. Нигезләмәнең 6.1. пунктына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

“Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда, һәм (яисә) гавами сервитутта каралган;

1.4. Нигезләмәнең 5.14 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта әлеге карарлар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар керми, ул "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктының 1, 1_1, 5, 9 һәм 10 бүлекләрендә каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла.";

000053

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерегә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгы В.И.Никитин